**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ЛАИШЕВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ МАЛОЕЛГИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
422619, с. Малая Елга
ул.Советская, д.58
тел: 8-(84378) -3-25-16
факс: 8-(84378) -3-25-16
e-mail:Melg.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЕЧЕ ЕЛГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**
422619, Кече Елга авылы,
Совет урамы, 58нче йорт,
тел: 8-(84378) -3-25-16
факс: 8-(84378) -3-25-16
e-mail:Melg.La@tatar.ru

2024 елның 6 сентябре 35 номер

КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Кече Елга авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмә хакында» Кече Елга авыл җирлеге Советының 2023 елның 23 гыйнварындагы 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024елның 08 августындагы 289-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Кече Елга авыл җирлеге советы, КАРАР ИТТЕ:

1.«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Кече Елга авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмә хакында» Кече Елга авыл җирлеге Советының 2023 елның 23 гыйнварындагы 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә, түбәндәге редакциядә бәян итеп:

4.6.4. пункт Планнан тыш күчмә тикшерү бары тик прокуратура органнары белән килештереп кенә үткәрелергә мөмкин, моңа 57 статьяның 1 өлешендәге 3 - 5 пунктлары һәм 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә уздыру очраклары керми.

4.9.5. пункт Күчмә тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында каралган карар кабул ителә алмый.

4.7.10 Пункт. Рейд тикшерүе прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин, моңа 248 - ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3-5 пунктлары һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12_1 өлешләре нигезендә үткәрелгән очраклар керми.

2.Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3.Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан  Республикасы**
**Лаеш  муниципаль  районы  Кече Елга**
**авыл  җирлеге Советы рәисе** **Р.З.Хисамов**